**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын төзү турында» 2017 елның 26 маендагы ПУ-441 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 22 декабрендәге ПУ-1153 номерлы, 2018 елның 19 февралендәге ПУ-177 номерлы, 2018 елның 6 июнендәге ПУ-406 номерлы һәм 2018 елның 21 сентябрендәге ПУ-678 указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) оештыру комитеты составыннан Ф.С. Габделганиевны, Р.И. Вәлиевны, Г.Р. Нигъмәтуллинаны, АА. Фоминны, Р.Р. Йосыповны чыгарырга;

б) оештыру комитеты составына кертергә:

Әхмәдиева Роза Шәйхәйдәр кызын – Казан дәүләт мәдәният институты ректорын (килешү буенча);

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Низамова Ләйсән Габделхан кызын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгын;

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

в) оештыру комитеты әгъзалары вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Э.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча)»;

Р.З. Закировның – «Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе (килешү буенча)»;

А.Р. Зариповның – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 26 февраль
№ ПУ-120